Республика Татарстан
Рыбно-Слободский
муниципальный район
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Кугарчинского сельского поселения
422662, с.Кугарчино.
ул.Советская , дом 62 а

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль районы
Кугәрчен авыл җирлеге
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422662, Кугәрчен авылы.
Совет урамы, 62 а йорт

тел:8(84361)28-5-89, факс :8(84361)28-5-89 эл .почта Kugar.Rs@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 16 августы** **Күгәрчен ав.** **№ 40**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге территориясендә гомуми файдаланудагы җирләрдә үләнне, яфракларны яндыру урыннарын һәм алымнарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы, 2016 елның 20 сентябрендәге 390 номерлы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Янгынга каршы режим турында" 2012 елның 20 сентябрендәге 390 номерлы, № 947 " Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районыКүгәрченавыл җирлеге территориясендә торак пунктларның янгынга каршы тотрыклылыгын арттыру максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районыКүгәрченавыл җирлеге торак пунктларының гомуми кулланылыштагы җирләрендә учак ягу, шулай ук якындагы саклану объектыннан 50 метр ераклыкта булган урыннарда һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренең 72.1 пунктында күрсәтелгән шартларда үлән, яфракларны яндыру тыела.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертелгән чорда үз көчен югалтмый.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районыКүгәрчен авыл җирлегенең Күгәрчен авылы, Совет урамы, 62а йорт; Зәңгәр-Күл авылы, Тукай урамы, 3 а йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күгәрчен авыл җирлеге Башлыгы А.Т.Сафин